КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 июль г.Казань № 633

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган Татарстан Республикасы оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасындагы социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 28 декабрь, 890 нчы; 2010 ел 21 сентябрь, 749 нчы; 2011 ел, 29 июль, 606 нчы; 2012 ел, 9 июнь, 500 нче; 2013 ел, 28 июнь, 444 нче; 2014 ел, 5 июнь, 380 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 734 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 769 нчы; 2015 ел, 21 сентябрь, 693 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 830 нчы; 2016 ел, 14 гыйнвар, 8 нче; 2016 ел, 3 ноябрь, 812 нче; 2017 ел, 13 июнь, 374 нче; 2018 ел, 19 февраль, 93 нче; 2018 ел, 21 апрель, 277 нче; 2019 ел, 27 февраль, 135 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда вәкаләтле органга әлеге максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсы турындагы нигезләмәдә:

2.1 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вәкаләтле орган – Конкурсны үткәрү буенча оештыру функцияләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы; аңа бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына грантлар бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә ирештерелә;»;

4.2 нче пунктта:

беренче абзацта «шулай ук коммерциягә карамаган оешмалар (аларга мөнәсәбәтле ябу яки үзгәртеп оештыру турында карар кабул ителгән)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Конкурста шулай ук заявкаларны кабул итү вакыты башлану планлаштырылган ай алдыннан килә торган айның бересенә түбәндәге коммерциягә карамаган оешмалар катнаша алмый:

бетерү, банкротлык процессында булган;

чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик затлары булган;

бу Нигезләмә максатлары өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булган;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булган;

субсидияләрне, грантларны, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган.»;

4.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Коммерциягә карамаган оешмалар Конкурста катнашу турындагы заявкаларны кабул итү комиссиясенә бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча кертә, аңа түбәндәгеләрне терки:

коммерциягә карамаган оешманы дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәләрен яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазе күчермәсен;

салым органында коммерциягә карамаган оешманы исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсен;

коммерциягә карамаган оешма уставы күчермәсен;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе имзалаган һәм мөһере белән расланган коммерциягә карамаган оешманың штат расписаниесе күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан заявкалар кабул итү вакыты башланганга кадәр өч айдан да иртәрәк бирелмәгән, заявка бирүче турында мәгълүматлары булган өземтә күчермәсен;

коммерциягә карамаган оешманың Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавы турында салым органының белешмә кәгазен;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлеген җайга сала торган федераль законнарның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары турында» 2006 елның 15 апрелендәге 212 номерлы карары нигезендә коммерциягә карамаган оешма тарафыннан Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә кертелгән үткән финанс елы өчен эшчәнлек турындагы хисап күчермәсен;

субсидияләрне, грантларны, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмауны раслый торган, коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзалаган белешмә кәгазен;

коммерциягә карамаган оешманың бетерү һәм банкротлык процессында булмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе имзалаган белешмә кәгазен;

теркәлә торган барлык документларның исеменнән торган бирелүче документлар исемлекләрен.

Бирелә торган грант исәбеннән коммерциягә карамаган оешма социаль әһәмияткә ия булган проект бюджетында түбәндәге чыгымнарны күздә тотарга хокуклы:

хезмәт, шул исәптән штат хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү, шулардан проект җитәкчесенең хезмәте өчен түләү;

товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр, аренда өчен түләү;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

мөлкәт хокукларын, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокуклар сатып алу;

командировкалар;

ирекле́ләр чыгымнарын каплау;

социаль әһәмияткә ия булган проектны тормышка ашыруның календарь планында каралган чараларны гамәлгә ашыруга турыдан-туры бәйле булган башка чыгымнар.

Социаль әһәмияткә ия булган проект бюджетында грант акчасы исәбеннән түбәндәге чыгымнарны финанслау каралмаска тиеш:

эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм коммерциягә караган оешмаларга ярдәм күрсәтүгә бәйле булган;

социаль әһәмияткә ия булган проект белән турыдан-туры бәйле булмаган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга;

сәяси партияләргә һәм сайлау кампанияләренә ярдәм күрсәтүгә;

митинглар, демонстрацияләр, пикетлар үткәрүгә;

фундаменталь фәнни тикшеренүләргә;

алкогольле эчемлекләр һәм тәмәке продукциясе сатып алуга;

штрафлар түләүгә;

чит ил валютасы сатып алуга (югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш).

Китаплар, уку әсбаплары, методик материаллар, альбомнар бастырып чыгару, фильмнар төшерү, телевизион һәм радиотапшырулар чыгару аның максаты булган социаль әһәмияткә ия булган проектлар бюджетларында шулай ук грант акчасы исәбеннән автор бүләкләүләре һәм гонорарлар түләү, әлеге материалларны тарату яки күрсәтү (демонстрацияләү) чыгымнарын финанслау күздә тотылмаска тиеш.

Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар тегелгән, нумерланган һәм коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле заты имзасы һәм мөһере белән расланган булырга тиеш. Барлык документлар да ачык бастырылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми (коммерциягә карамаган оешманың мөһере белән беркетелгән һәм вәкаләте заты имзасы белән расланган төзәтүләрдән тыш).

Коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле заты күрү буенча инвалид булган очракта, ул заявкага һәм аңа теркәлә торган документларга имза куйганда аның үз кулы белән куела торган имзасының механик күчерү чарасы ярдәмендә төшерелә торган факсимиль күчермәсен кулланырга хокуклы.

Әлеге хокукны тормышка ашыру максатларында, коммерциягә карамаган оешманың күрү буенча инвалид булган вәкаләтле заты заявкага өстәмә рәвештә шәхесен раслый торган документ күчермәсен, күрү буенча инвалидның үз кулы белән куя торган имзасы аның үз кулы белән куйган имзасының факсимиль күчермәсенә тәңгәл булуын раслау турындагы нотариаль таныклыкның нотариат турындагы законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә бирелгән күчермәсен терки.

Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар кәгазьдә һәм электрон йөрткечләрдә (doc, excel форматларында флеш-туплагычларда) турыдан-туры кабул итү комиссиясенә тапшырыла яки аңа почта аша җибәрелә.

Бер коммерциягә карамаган оешма бер генә заявка бирә ала, аның составында Конкурста катнашу өчен бер генә социаль әһәмияткә ия булган проект тапшырыла.»;

4.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Заявканы һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү комиссиясе заявкаларны кабул итеп бетергән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган

10 көн эчендә бу Нигезләмә белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә тикшерә.»;

5.2 нче һәм 5.3 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Экспертлар заявкаларны тикшереп бетергән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 21 көн эчендә бу Нигезләмәнең VI бүлегендә күздә тотылган тәртиптә заявкаларны һәм аларга теркәлгән документларны карый һәм эксперт бәяләмәләрен Вәкаләтле органга тапшыра.

Вәкаләтле орган экспертлар тарафыннан бәяләмәләр тапшырылган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә баллар суммасы буенча заявкаларның рейтингын төзи, ул ике эксперт куйган һәр критерий буенча баллар суммасының уртача арифметик мәгънәсе буларак исәпләнә һәм заявкалар рейтингын формалаштыру турындагы мәгълүматларны Конкурс комиссиясенә тапшыра.

Берничә заявканың йомгаклау рейтинглары бертөрле булса, иң аз тәртип саны башка заявкалардан иртәрәк кергән Конкурста катнашу турындагы заявкага куела.

5.3. Конкурс комиссиясе Вәкаләтле органнан заявкалар рейтингын формалаштыру турында мәгълүмат алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә заявка рейтингының минималь мәгънәсен (алга таба – заявка рейтингының минималь мәгънәсе) билгели, аны керткән Конкурста катнашучы җиңүче дип танылырга мөмкин.

Заявка рейтингының минималь мәгънәсе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$М = \frac{ОКБ}{N},$$

монда:

М – заявка рейтингының минималь мәгънәсе;

ОКБ – заявкалар буенча барлык экспертлар тарафыннан куелган балларның гомуми суммасы;

N – Конкурста катнашучылар саны.

Конкурс комиссиясе заявкалар рейтингының минималь мәгънәсен исәпләп чыгарган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә номиналь коэффициент күләме турында карар кабул итә һәм заявка рейтингының чик мәгънәсен билгели (алга таба – заявка рейтингының чик мәгънәсе), аны керткән Конкурста катнашучы җиңүче дип танылa.

Заявка рейтингының чик мәгънәсе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Р = М \times К,$$

монда:

Р – заявка рейтингының чик мәгънәсе;

М – заявка рейтингының минималь мәгънәсе;

К – Конкурс комиссиясе карары белән билгеләнә торган, 0,01 адымга арттырып, 1гә тигез булган номиналь коэффициент.

Заявка рейтингының чик мәгънәсен билгеләгәннән соң, Конкурс комиссиясе рейтингның чик мәгънәсен раслаган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Конкурста җиңүчеләрне билгели.

Конкурста җиңүчеләр исемлеге Конкурс комиссиясенең Конкурста җиңүчеләрне билгеләү буенча утырышы үткәрелгәннән соң өч эш көне эчендә Конкурс комиссиясе карары белән рәсмиләштерелә.»;

Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле $5.4^1$ нче пункт өстәргә:

«$5.4^1$. Конкурс комиссиясе Конкурста җиңүчеләрне билгеләгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә җиңүчеләргә бирелә торган грантлар күләмнәре турында карар кабул итә, ул түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_i = \frac{S}{SUM} \times a_i,$$

монда:

$C_i$ – i-коммерциягә карамаган оешманың – Конкурста җиңүченең грант күләме;

S – грантлар күләме;

SUM – Конкурста җиңүчеләр дип билгеләнгән тәртиптә танылган коммерциягә карамаган оешмаларның заявкалары буенча барлык экспертлар тарафыннан куелган баллар суммасы;

$a_i$ – экспертлар бәясе буенча i-коммерциягә карамаган оешма – Конкурста җиңүче тарафыннан җыелган балларның гомуми суммасы.

i-коммерциягә карамаган оешманың бу пункт нигезендә билгеләнгән грант күләме i-коммерциягә карамаган оешма тарафыннан сорала торган грант күләменнән артыграк булса, i-коммерциягә карамаган оешманың грант күләме i-коммерциягә карамаган оешма тарафыннан соралган грант күләменә тигез дип билгеләнә, ә аермасы бу пункт нигезендә конкурс буенча сайлап алынган башка коммерциягә карамаган оешмалар арасында бүленә.»;

6.1 нче пунктта «социаль әһәмиятле проектлар» сүзләрен «заявкалар һәм аларга теркәлгән документлар»» сүзләренә алыштырырга;

6.2 – 6.4 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Һәр заявканы һәм аңа теркәлә торган документларны ике эксперт карый, аларның берсе Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы вәкиле булмаган зат булырга тиеш. Экспертлар заявкаларны һәм аларга теркәлә торган документларны конкурс буенча сайлап ала торган һәр критерий таләпләреннән чыгып 10 баллы шкала (1 дән 10 га кадәр) буенча бәяли һәм эксперт бәяләмәсен әзерли. Заявкаларны һәм аларга теркәлә торган документларны караган экспертлар бәясе арасындагы аерма 35 балл һәм аннан да күбрәк булса, заявка һәм аңа теркәлә торган документлар Конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә торган өченче эксперт тарафыннан карала.

6.3. Экспертлар коммерциягә карамаган оешмаларның вәкилләре булса, алар бу оешмаларның – Конкурста катнашучыларның заявкаларын һәм аларга теркәлгән

документларын бәяләүдә катнаша алмый. Экспертиза үткәрү барышында экспертка билгеле булган мәгълүмат конфиденциаль була һәм таратылмаска тиеш.

6.4. Конкурс комиссиясе әгъзасы Конкурска тәкъдим ителгән заявкаларга һәм аларга теркәлгән документларга экспертиза үткәрүдә катнашырга хокуксыз.»;

8.1 нче пунктта:

дүртенче һәм бишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс оештыруны һәм үткәрүне.

Вәкаләтле орган грант алучылар белән социаль әһәмияткә ия булган проектларны максатчан финанслау (грантлар бирү) турында шартнамәләр (алга таба – шартнамә) төзүне, грантлардан максатчан файдалану һәм грантлар файдалану нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләренә ирешү турындагы агымдагы һәм йомгаклау хисапларын гомумиләштерүне, гомумиләштерелгән мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрүне гамәлгә ашыра.»;

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип санарга;

9.1 нче пунктның алтынчы абзацында «Конкурста җиңүчеләр исемлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертә» сүзләрен төшереп калдырырга;

10.2 нче пунктта «финанслашу шартларында» сүзләреннән соң «, һәм Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан грант алучының грант бирү һәм аннан файдалану шартларын, максатларын, тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә грант алучының ризалыгы булганда» сүзләрен өстәргә;

10.4 – 10.6 нчы пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.4. Грант алучылар грантлардан проект бюджеты нигезендә максатчан файдаланырга һәм гранттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең билгеләнгән мәгънәләренә ирешүне тәэмин итәргә тиеш. Грант бирү Вәкаләтле орган һәм грант алучы арасында төзелә торган шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

Шартнамә Конкурс комиссиясе тарафыннан Конкурста һәр номинация буенча җиңүчеләр һәм грантлар күләмнәре билгеләнгән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә төзелә.

Вәкаләтле орган Конкурс комиссиясе тарафыннан Конкурста һәр номинация буенча җиңүчеләр һәм грантлар күләмнәре билгеләнгән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 10 көн эчендә грант алучыга Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча Вәкаләтле орган һәм грант алучы арасында грант бирү турындагы шартнамә проектын ике нөсхәдә җибәрә.

Грант алучы шартнамә проектын алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган биш көн эчендә шартнамәнең ике нөсхәсенә имза куя һәм Вәкаләтле органга җибәрә.

Грант алучыдан имзаланган шартнамәне алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган биш көн эчендә Вәкаләтле орган шартнамәгә имза куя һәм шартнамәнең бер нөсхәсен грант алучыга җибәрә.

Әгәр дә грант алучы грант бирү турындагы шартнамә проектын алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган биш көн эчендә үз ягыннан имзаланган

шартнамәне Вәкаләтле органга кертмәсә, бу грант алучыга грант бирү турындагы карар гамәлдән чыгарылган дип санала.

Шартнамәдә грантның максатчан билгеләнеше һәм аның күләме, грантны тоту юнәлешләре (социаль әһәмиятле проектның бюджеты), грант бирү тәртибе һәм аны күчерү вакытлары, нәтиҗәлелек күрсәткечләре, шул исәптән аларның максатчан мәгънәләре, шартнамә шартларын бозган өчен җаваплылык, гранттан файдалану һәм гранттан файдалану нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләренә ирешү турында хисап кертү тәртибе, вакытлары һәм формасы, грант акчасы максатчан файдаланылмаган һәм/яки аны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән гранттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү буенча йөкләмәләр бозылганда грантны кире кайтару тәртибе һәм вакытлары, грант алучының хисап финанс елында грантның файдаланылмаган өлешләрен кире кайтару очраклары, грант акчасы исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю (югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операциялардән тыш), Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан грант алучының грант алу шартларын, максатларын, грант бирү һәм аннан файдалану тәртибен үтәвенә тикшерүләрне башкару өчен грант алучының ризалыгы карала.

Грант Вәкаләтле орган тарафыннан Вәкаләтле орган счетына акча кергәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә грант алучының грант алучы тарафыннан Россия кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетына шартнамә нигезендә күчерелә.

Грант алучыга грант бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

грант алучы тарафыннан кертелгән документларның бу Нигезләмәдәге 4.3 нче пунктта документларга карата билгеләнгән таләпләргә туры килмәвен ачыклау яки әлеге документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

грант алучы тарафыннан кертелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавын ачыклау;

грант алучы грант бирү турындагы шартнамә проектын алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган биш көн эчендә үз ягыннан имзаланган шартнамәне Вәкаләтле органга кертмәү.

Грант алучы грант акчасы керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

10.5. Грант Вәкаләтле органның һәм (яки) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә грант алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

грант алучы грант алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар керткәндә;

гранттан максатчан файдаланмаганда, бу Нигезләмә һәм шартнамә белән күздә тотылган грант бирү һәм гранттан файдалану шартлары, тәртибе үтәлмәгәндә һәм гранттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешә алмаганда.

Грантны максатка ярашлы файдаланмаган очракта, ул максатка ярашлы файдаланмаган суммада кире кайтарылырга тиеш.

Шартнамә белән күздә тотылган очракларда, грантның хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше грант бирелгән елдан соң килә торган елның 1 декабренә кадәр грант алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Грант алучы грантны кире кайтару вакытын бозса, Вәкаләтле орган бу пунктның беренче һәм бишенче абзацларында билгеләнгән вакыт чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару чараларын күрә.

Грант алучы тарафыннан грант акчасын ирекле рәвештә кире кайтару вакыты бозылган очракта, грант алучы грант акчасын Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына үз вакытында күчермәгән өчен кире кайтарылырга тиешле грант суммасыннан чыгып грантның грант алучыда булган һәр көненә 0,1 процент күләмендә пеня түли.

Грант алучы тарафыннан шартнамә белән күздә тотылган йөкләмәләр үз вакытында үтәлмәгән очракта, грант алучы пеня түли. Пенялар шартнамә белән билгеләнгән йөкләмәләрне үтәү вакыты чыккан көннән соң килә торган көннән башлап, шартнамә белән күздә тотылган йөкләмәләрне үз вакытында үтәмәгән һәр көн өчен грант суммасыннан Россия Федерациясе Үзәк банкының төп ставкасы пеняларын түләү көненә гамәлдә булган өч йөздән бер күләмендә исәпләнә, әгәр дә бу Нигезләмә һәм шартнамә белән башкасы каралмаган булса. Грант алучыга грант күчергәннән соң грант алучының грант алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар кертүе ачыкланган очракта, грант алучы бирелгән грант күләменнән биш процент күләмендә штраф түли.

10.6. Грант алучының гранттан максатчан файдалануын тикшерүдә тоту һәм гранттан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Грант бирүнең максатчан күрсәткечләре Вәкаләтле орган тарафыннан шартнамәдә билгеләнә.

Гранттан максатчан файдалануны тикшерү һәм гранттан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү өчен грант алучы Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы таләбе буенча тотылган чыгымнарны раслый торган документларны (төп нөсхәләрен һәм/яки коммерциягә карамаган оешма тарафыннан расланган күчермәләрен) бирергә тиеш.»;

Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсы турындагы нигезләмәгә теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсы турындагы нигезләмәгә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 30 июль, 633 нче карары редакциясендә)

Форма

| | |
|---|---|
| Теркәү номеры | |

Коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсында катнашуга
ЗАЯВКА

## 1. Заявка бирүче оешма

| | |
|---|---|
| 1. Оешма исеме | |
| 2. Оешманың кыскартылган исеме | |
| 3. ОГРН | |
| 4. ИНН | |
| 5. КПП | |
| 6. Оешманы дәүләт теркәвенә алу датасы | |
| 7. Оешманың юридик адресы | <br>Оешманың теркәлү урыны күрсәтелә: почта индексы, Татарстан Республикасы, муниципаль район (Казан шәһәре, Яр Чаллы шәһәре шәһәр округларыннан башка), шәһәр (торак пункт), урам, йорт номеры, корпус номеры (булган очракта), офис (фатир) номеры. |
| 8. Оешманың факттагы адресы | <br>Оешманың урнашу урыны күрсәтелә: почта индексы, Татарстан Республикасы, муниципаль район (Казан шәһәре, Яр Чаллы шәһәре шәһәр округларыннан башка), шәһәр (торак пункт), урам, йорт номеры, корпус номеры (булган очракта), офис (фатир) номеры. |
| 9. Оешманың элемтәгә керү өчен телефоннары | +7<br>Оешма белән элемтәгә кереп булган һәм һәркем файдалана алган урыннарда, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла торган телефоннар номерлары күрсәтелә. |

| | |
|---|---|
| 10. Оешмага юридик әһәмиятле мәгълүматлар җибәрү өчен электрон почта адресы | |
| | Оешмага юридик әһәмиятле мәгълүматлар һәм документлар җибәреп була торган электрон почта адресы күрсәтелә. |
| 11. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә оешма | «Әйе» яки «Юк» дип күрсәтелә |
| | «Әйе» дип күрсәткән очракта, әлеге пунктның пунктчалары тутырыла.<br>«Юк» дип күрсәткән очракта, әлеге пунктның пунктчаларында «Юк» дип языла. |
| 11.1. Веб-сайты | |
| 11.2. Татарстан Республикасының коммерциягә карамаган оешмалары порталында биты (http://nkort.ru) | |
| 11.3. Социаль челтәрләр-дәге төркемнәре | |
| | Оешманың социаль челтәрләрдәге төркеменә/битенә сылтамалар өтер аша күрсәтелә (мәсәлән, «ВКонтакте», «Фейсбук», «Инстаграм» һ.б.). |
| 12. Оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) | |
| 12.1. Оешма җитәкчесенең вазыйфасы | |
| 12.2. Оешма җитәкчесенең элемтәгә керү өчен телефоны | +7 |
| | Телефоннар берничә булган очракта, номерлар өтер аша күрсәтелә. |
| 12.3. Оешма җитәкчесенең электрон почта адресы | |
| | Электрон почта адресы булган очракта күрсәтелә, булмаган очракта, «Юк» дип куела. |
| 13. Проект җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) | |
| | Проектның җитәкчесе булганда күрсәтелә, булмаган очракта, пунктта һәм пунктчаларда «Юк» дип куела. |
| 13.1. Проектның җитәкчесе турында өстәмә мәгълүмат | |
| | Проектның җитәкчесе булганда, гыйльми исеме, гыйльми дәрәҗәсе, күмәк органнарда әгъзалыгы һ.б. күрсәтелә, булмаган очракта, «Юк» дип куела. |
| 13.2. Проект җитәкчесенең элемтәгә керү өчен телефоны | +7 |
| | Телефоннар берничә булган очракта, номерлар өтер аша күрсәтелә. |
| 13.3. Проект җитәкчесенең электрон почта адресы | |
| | Электрон почта адресы булган очракта күрсәтелә, булмаган очракта, «Юк» дип куела. |

| | |
|---|---|
| 14. Баш бухгалтер (бухгалтер) | <br>Баш бухгалтер (бухгалтер) булган очракта яки оешмада тиешле функцияләрне башкаручы зат турында мәгълүматлар күрсәтелә, булмаган очракта, «Юк» дип куела. |
| 14.1. Баш бухгалтерның (бухгалтерның) элемтәгә керү өчен телефоны | +7<br>Телефоннар берничә булган очракта, номерлар өтер аша күрсәтелә. |
| 14.2. Баш бухгалтерның (бухгалтерның) электрон почта адресы | <br>Электрон почта адресы булган очракта күрсәтелә, булмаган очракта, «Юк» дип куела. |
| 15. Оешманың төп эшчәнлек төрләре | Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү, социаль ярдәм күрсәтү һәм аларны яклау<br>Мәгариф, аң-белем бирү өлкәсендә эшчәнлек, мондый эшчәнлеккә булышлык күрсәтү<br>Фән өлкәсендә эшчәнлек, мондый эшчәнлеккә булышлык күрсәтү<br>Мәдәният, сәнгать, кинематография һәм анимация өлкәсендә эшчәнлек<br>Сәламәтлек саклау, гражданнарның сәламәтлеген профилактикалау һәм саклау, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау өлкәсендә эшчәнлек, мондый эшчәнлеккә булышлык күрсәтү<br>Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек, мондый эшчәнлеккә булышлык күрсәтү<br>Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм хайваннарны яклау<br>Хәйрия эшчәнлеге<br>Хәйриячелеккә булышлык күрсәтү<br>Иреклелек өлкәсендә эшчәнлек<br>Гражданнарның әхлакый-психологик халәтен яхшырту, шәхеснең рухи үсешенә ярдәм итү өлкәсендә эшчәнлек<br>Иҗтимагый әһәмиятле яшьләр башлангычларына, проектларга, балалар һәм яшьләр хәрәкәтенә, балалар һәм яшьләр оешмаларына булышлык күрсәтү<br>Милләтара хезмәттәшлекне үстерү, Россия Федерациясе халыкларының үзенчәлеген, мәдәниятен, телләрен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм яклау<br>Россия Федерациясе гражданнарына патриотик, шул исәптән хәрби-патриотик тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлек<br>Ватанны саклаучыларның билгесез хәрбиләр җирләнгән урыннарын һәм җирләнмәгән калдыкларын ачыклауга, һәлак булганнарның һәм хәбәрсез югалганнарның исемнәрен билгеләүгә юнәлдерелгән эзләү эшләрен үткәрү<br>Тарихый, мәдәни, табыну яки табигатьне саклау әһәмиятенә ия булган объектларны һәм территорияләрне, җирләү урыннарын саклау һәм карап тоту<br>Гражданнарга түләүсез яки ташламалы нигездә юридик ярдәм күрсәтү, халыкка хокукый аң-белем бирү, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау эшчәнлеге<br>Коммерциягә карамаган оешмаларга түләүсез яки ташламалы нигездә юридик ярдәм күрсәтү<br>Наркотик чаралар яки психотроп матдәләрне законсыз куллануны гамәлгә ашыручы затларны социаль һәм хезмәт ягыннан реинтеграцияләү, медицина һәм социаль тернәкләндерү<br>Балигъ булмаганнарның караучысызлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау эшчәнлегендә катнашуны да кертеп, гражданнарның социаль куркыныч үз тотыш формаларын профилактикалау<br>Табигый бәла-казалар, экологик, техноген яисә башка һәлакәтләр аркасында зыян күргәннәргә ярдәм күрсәтү;<br>Социаль, милли, дини низаглар аркасында зыян күргәннәргә, качакларга һәм мәҗбүри күченүчеләргә ярдәм күрсәтү<br>Мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү<br>Янгыннарны профилактикалауда һәм (яки) сүндерүдә һәм һәлакәттән коткару эшләрен үткәрүдә катнашу<br>Халыкны табигый бәла-казалар, экологик, техноген яисә башка һәлакәтләр нәтиҗәләрен бетерүгә, бәхетсезлек очракларын кисәтүгә әзерләү;<br>Хезмәт ресурсларының мобильлеген арттыруга булышлык күрсәтү |

| | |
|---|---|
| | Сәяси репрессияләр корбаннары истәлеген мәңгеләштерү<br>Коррупциягә каршы эшчәнлек (җәмгыятьтә коррупцияле тәртипкә карата түземсезлекне формалаштыруны кертеп).<br>Үзегезнекен күрсәтегез: ____________________________________________________<br>Тәкъдим ителә торган исемлектән оешма тарафыннан үз уставы нигезендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлекнең иң күбе 5 төп төре күрсәтелә. |
| 16. Оешманың эш тәҗрибәсе булган максатчан төркемнәр | 1. Алкогольгә һәм наркотикларга бәйле кешеләр, шулай ук бәйлелекнең башка авыр төрләреннән интегүче затлар<br>2. Качаклар<br>3. Билгеләнгән яшәү урыны булмаган затлар<br>4. Ветераннар<br>5. Балалар һәм үсмерләр<br>6. Хатын-кызлар<br>7. Иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлар<br>8. Мигрантлар<br>9. Күпбалалы гаиләләр<br>10. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр<br>11. Яшьләр һәм студентлар<br>12. Пенсионерлар<br>13. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар<br>14. Тормышта авыр хәлдә калган затлар<br>15. Онкологик авырулар белән авыручылар<br>16. Авыр авырулар белән авыручы затлар<br>17. Көч кулланудан зыян күргән затлар<br>18. Һәлакәтләрдән һәм гадәттән тыш хәлләрдән зыян күргән затлар<br>19. Әйләнә-тирә мохит мәсьәләләрен профилактикалауда һәм хәл итүдә катнашучы затлар<br>20. Тарихый истәлекне саклауда катнашучы затлар;<br>21. Йортсыз хайваннарга ярдәм күрсәтүдә катнашучы затлар;<br>22. Мәдәният өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүдә һәм профилактикада катнашучы затлар;<br>23. Спорт һәм яшьләр сәясәте өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүдә һәм профилактикада катнашучы затлар;<br>24. ____________________________________________________________<br>Заявка бирүченең теләге буенча тутырыла. Тәкъдим ителә торган исемлектән сайлап алына һәм (яки) үзенеке өстәлә. |

17. Башка коммерциягә карамаган оешмаларда катнашу (әгъза булу)

| Исеме | ИНН / КПП / ОГРН | Адресы |
|---|---|---|
| | | |

Булган очракта күрсәтелә, булмаган очракта, «Юк» дип куела.

18. Коммерция оешмаларында катнашу (әгъза булу)

| Исеме | ИНН / КПП / ОГРН | Адресы |
|---|---|---|
| | | |

Булган очракта күрсәтелә, булмаган очракта, «Юк» дип куела.

| | |
|---|---|
| 19. Штаттагы хезмәткәрләр саны | |
| | Заявка бирү ае алдыннан килә торган айның бере хәленә карата. |
| 20. Ирекләләр (волонтерлар) саны | |
| | Заявка бирүнең агымдагы календарь елы өчен булганда күрсәтелә, булмаганда, «Юк» дип куела. |
| 21. Үткән ел өчен оешманың керемнәре (сумнарда), саннарны өтер һәм башка билгеләр куймыйча кертергә | |
| | Оешманың үткән ел өчен керемнәр суммасы (сумнарда, тиенсез) күрсәтелә. Әгәр дә нинди дә булса китерелгән бүлекчәләр буенча керемнәр булмаса, 0 (ноль) саны күрсәтелә. Әгәр дә оешма үткән календарь елда теркәлмәгән булса, барлык юлларда 0 (ноль) саны күрсәтелә. |

| | |
|---|---|
| 21.1. Федераль бюджеттан алынган акча | |
| 21.2. Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча | |
| 21.3. Җирле бюджетлардан алынган акча | |
| 21.4. Россия коммерциягә карамаган оешмалары грантлары, кертемнәре, иганәләре (Президент грантларыннан башка) | |
| 21.5. Президент грантлары | |
| 21.6. Россия коммерция оешмалары кертемнәре, иганәләре | |
| 21.7. Россия гражданнары кертемнәре, иганәләре | |
| 21.8. Чит ил оешмалары һәм чит ил гражданнары грантлары, кертемнәре, иганәләре | |
| 21.9. Товарлар сатудан, эшләр башкарудан, хезмәт күрсәтүләрдән, мөлкәт хокукларын реализацияләүдән керемнәр (табыш) | |
| 21.10. Сатудан тыш керемнәр (дивидендлар, депозитлар буенча процентлар һ.б.) | |
| 21.11. Башка керемнәр | |
| 22. Үткән ел өчен (гыйнвардан алып декабрьгә кадәр) файда алучылар саны: физик затлар, юридик затлар | |

Заявка бирү елы алдыннан килә торган календарь ел өчен заявка бирүче оешмадан түләүсез файдалар алган гражданнар һәм (яки) оешмалар саны күрсәтелә.

23. Соңгы өч ел эчендә тормышка ашырылган төп проектлар һәм программалар

| Т/с | Проект исеме | Финанслау күләме (сум) | Финанслау чыганагы | Үтәлү чоры | | Төп нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | башы | ахыры | |
| | | | | | | |

Мондый программаларны һәм проектларны тормышка ашыру вакытлары, аларны финанслау күләме һәм чыганагы, мондый проектларның исеме һәм төп нәтиҗәләре күрсәтелә. Финанслау чыганаклары вариантлары: Президент гранты; Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш министрлыгы субсидиясе; федераль бюджеттан башка субсидия; Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (грант); җирле бюджеттан субсидия (грант); бюджеттан тыш чыганаклардан грант; башка финанслау чыганагы.

24. Оешма карамагындагы матди-техник һәм мәгълүмати ресурслар

| |
|---|
| |

Заявка бирүченең теләге буенча тутырыла.

23.1. Бина урыннары

| |
|---|
| |

Бина урынының мәйданы һәм аннан файдалану хокукы төре, билгеләнеше күрсәтелә.

23.2. Җайланма

| |
|---|
| |

23.3. Башка

| |
|---|
| |

24. Массакүләм мәгълүмат чараларында басмалар:

| Басманың төре (мәкалә, видеосюжет, радиоэфир һ.б.) | Массакүләм мәгълүмат чаралары категориясе (газета, журнал, ТВ, радио, «Интернет» челтәре һ.б.) | Массакүләм мәгълүмат чараларының исеме | Басылып чыгу көне | Интернет-чыганакка сылтама (булганда) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Заявка бирүченең теләге буенча тутырыла. Массакүләм мәгълүмат чараларында заявка бирүче оешманың эшчәнлеге турында мәгълүмат басылып чыккан язмаларга сылтамалар күрсәтелә.

## 2. Проект турында

1. Конкурсның юнәлеше (темасы)

| |
|---|
| |

2. Конкурсның номинациясе

| |
|---|
| |

3. Тормышка ашыру өчен субсидия сорала торган проектның исеме

| |
|---|
| |

(иң күбе 300 символ)

4. Проектның тасвирламасы (резюме)

| |
|---|
| |

5. Проектны тормышка ашыра башлау көне

| |
|---|
| |

(ай, ел)

6. Проектны тормышка ашырып бетерү көне

| |
|---|
| |

(ай, ел)

7. Проектның хәл ителмәгән мәсьәләләрен һәм социаль әһәмиятен нигезләү

| |
|---|
| |

Проектның төп идеясе, проектның эчтәлеге һәм көтелә торган аеруча мөһим нәтиҗәләр барлыкка килгән проблеманы һәм хәл-торышны чагылдыра торган проектның текст презентациясе (иң күбе 2 500 символ).

8. Проектның максатчан төркемнәре

| |
|---|
| 1. Алкогольгә һәм наркотикларга бәйле кешеләр, шулай ук бәйлелекнең башка авыр төрләреннән интегүче затлар<br>2. Качаклар<br>3. Билгеләнгән яшәү урыны булмаган затлар<br>4. Ветераннар<br>5. Балалар һәм үсмерләр<br>6. Хатын-кызлар<br>7. Ирегеннән мәхрүм итү урыннарында булган затлар |

| | |
|---|---|
| | 8. Мигрантлар<br>9. Күпбалалы гаиләләр<br>10. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр<br>11. Яшьләр һәм студентлар<br>12. Пенсионерлар<br>13. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар<br>14. Тормышта авыр хәлдә калган затлар<br>15. Онкологик авырулар белән авыручылар<br>16. Авыр авырулар белән авыручы затлар<br>17. Көч куллануда зыян күргән затлар<br>18. Һәлакәтләрдән һәм гадәттән тыш хәлләрдән зыян күргән затлар<br>19. Әйләнә-тирә мохит мәсьәләләрен профилактикалауда һәм хәл итүдә катнашучы затлар<br>20. Тарихый истәлекне саклауда катнашучы затлар;<br>21. Йортсыз хайваннарга ярдәм күрсәтүдә катнашучы затлар;<br>22. Мәдәният өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүдә һәм профилактикада катнашучы затлар;<br>23. Спорт һәм яшьләр сәясәте өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүдә һәм профилактикада катнашучы затлар;<br>24. ________________________________________________ |
| | Тәкъдим ителә торган исемлектән сайлап алына һәм (яки) үзенеке өстәлә. |
| 9. Проектның максаты | |
| | Проектның бер максаты булдырыла. |
| 10. Проектның бурычлары | 1.<br>2. |
| 11. Проектның командасы | |
| | Проектта катнашучыларның фамилиясен, исемен, атасының исемен; эш урынын; вазыйфасын; квалификациясе булуын раслый торган документларны (кирәк булганда); катнашу характерын (хезмәткәр, гражданлык-хокукый характердагы шартнамә, ризалык бирү хатын, телдән килешү кәгазен) күрсәтергә. |

12. Проектның партнерлары

| Партнер | Ярдәм күрсәтүнең төре | Нигезләү |
|---|---|---|
| | | килешү / шартнамә |
| | | хат |
| | | башка |

Заявка бирүченең теләге буенча тутырыла. Проектны тормышка ашыруда мәгълүмати, консультация, оештыру, матди һәм (яки) башка ярдәм күрсәтергә әзер булган 5 проект партнерына (оешмага) кадәр күрсәтелә.

| | |
|---|---|
| 13. Проектны мәгълүмати тәэмин итү | |
| | Проектны гомумән һәм аның төп чараларын массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» челтәрендә яктырту ни рәвешле тәэмин ителәчәге күрсәтелә (иң күбе 1000 символ). |

14. Саны буенча нәтиҗәләр

| Күрсәткеч | Күрсәткечнең план буенча мәгънәсе |
|---|---|
| | |

Проектны тормышка ашыру чорында ирешергә планлаштырыла һәм төгәл, санлы күрсәткечләрдә үлчәнә торган нәтиҗәләр формалаштырыла.

| | |
|---|---|
| 15. Сыйфаты буенча нәтиҗәләр | |
| | Проектны тормышка ашыру чорында ирешергә планлаштырыла һәм санлы мәгънәләрдә үлчәнми торган нәтиҗәләр күрсәтелә (социумдагы уңай үзгәрешләр, төгәл социаль мәсьәләләрне хәл итү, максатчан төркемнең тормыш сыйфатын яхшырту һ.б.; иң күбе 1 000 символ). |
| 16. Проектны алга таба үстерү | |
| | Алдагы елларда тормышка ашырырга планлаштырыла торган чаралар күрсәтелә. |
| 17. Алга таба проектны ресурслар белән тәэмин итү чыганаклары | |
| | Заявка бирүченең теләге буенча тутырыла. |

## 3. Проектны тормышка ашыруның календарь планы

| Т/с | Бурыч* | Чара | Башлау көне | Тәгәлләү көне | Көтелә торган нәтиҗәләр (сан һәм сыйфат күрсәткечләрен күрсәтеп) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

* Бурычлар «Проект турында»гы бүлекдән күчерелә. Календарь планда «Проект турында»гы бүлектә моңа кадәр күрсәтелгәннәрдән тыш башка бурычларны күрсәтү рөхсәт ителми.

## 4. Проектның бюджеты

| Т/с | Чыгымнар исеме | Үз акчасы* | Сорала торган акча | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | Итого | | | |

* Заявкага проектны тормышка ашыру өчен чыгымнарны үз акчасы белән финанслаштыруны раслый торган документлар тегеп куела.

Проект бюджетына комментарийлар:

| |
|---|
| |

(иң күбе 1 000 символ)

Заявкага түбәндәгеләр теркәлә:

| Т/с | Теркәлгән документның исеме | Битләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Заявкада бирелгән барлык мәгълүмат, шулай ук өстәмә материаллар дөрес дип белдерәм һәм бу заявкадагы һәм үзем тәкъдим иткән теләсә нинди башка документлардагы минем шәхси мәгълүматларымны вәкаләтле орган тарафыннан эшкәртүгә үз ризалыгымны бирәм. Вәкаләтле орган шәхси мәгълүматларны системалаштырырга, тупларга, сакларга, төгәлләштерергә (яңартырга, үзгәртергә), кулланырга, таратырга (шул исәптән өченче затларга тапшырырга), исемсезләргә, туктатырга һәм юк итәргә мөмкин.

Заявка бирүче оешма җитәкчесе

_________________________ (имзасы)

_________________________ (Ф.И.Ат.ис.)

М.У.

Датасы: _________________________